КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 декабрь г.Казань № 1294

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 974 нче; 2016 ел, 14 гыйнвар, 12 нче; 2016 ел, 2 ноябрь, 807 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1094 нче; 2017 ел, 27 июнь, 441 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел,

27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 апрель, 296 нчы; 2018 ел, 26 ноябрь, 1053 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2019 ел, 28 август, 732 нче; 2019 ел, 7 сентябрь, 892 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1248 нче; 2020 ел, 15 май, 391 нче; 2020 ел, 18 август, 704 нче; 2020 ел, 25 сентябрь, 873 нче; 2020 ел, 25 декабрь, 1190 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 26 нчы; 2021 ел, 1 февраль, 45 нче; 2021 ел, 21 июль, 627 нче; 2021 ел, 13 август, 719 нчы; 2021 ел, 15 ноябрь, 1075 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «700000Р.16.1.ЖХ86АА21000 | эш | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | эшнең эчтәлеге | объектларга һәм бүлмәләргә техник һәм алардан файдалану хезмәте күрсәтүне тәэмин итү, шулай ук әлеге объектларны һәм бүлмәләрне, җиһазны һәм алар янындагы территорияне тиешле хәлдә карап тоту | эш башкару шарты | даими | торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, шәһәр төзелеше эшчәнлеге, төзелеш һәм архитектура | Хезмәт күрсәтүләрнең, эшләр башкаруның төбәк исемлегеннән сайлау»; |

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «730000Р.16.1.ОН19АА83000 | эш | фәнни-методик тәэмин итү | | | | | мәгариф һәм фән | Хезмәт күрсәтүләрнең, эшләр башкаруның төбәк исемлегеннән сайлау»; |

8.1 пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Татарстан Республикасының Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе»;

23.12 пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23.12. «Костер» республика яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин